**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1504**
**07.03.2023**

«Татар малае» (5-8 сыйныф укучылары)
муниципаль конкурсын оештыру
һәм үткәрү турында

Башкарма комитетның 2021 елның 29 октябрендәге 7116 номерлы карары белән расланган «2022-2024 елларга Яр Чаллы шәһәрендә дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасын үтәү йөзеннән, яшь талантларны ачыклау һәм үстерү, балаларны туган телгә, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасына җәлеп итү, эстетик тәрбияләү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәгариф идарәсенә «Татар малае» (5-8 сыйныф укучылары) муниципаль конкурсын (алга таба - конкурс) оештыруны һәм үткәрүне тәэмин итәргә.

2. Расларга:

1) конкурс үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә чараны оештыру һәм үткәрү буенча чыгымнарны финанслауга акча бүлеп бирүне 2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Мәгариф өлкәсендә башка мәсьәләләр» 0709 бүлеге (бүлекчәсе) буенча каралган акчалар хисабына 50 000,00 (илле мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 7 мартындагы
1504 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Татар малае» (5-8 сыйныф укучылары) муниципаль конкурсын үткәрү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. «Татар малае» (5-8сыйныф укучылары) муниципаль конкурсы (алга таба – конкурс) яшь талантларны ачыклау һәм үстерү, балаларны туган телгә, Татарстан Республикасының тарихи-мәдәни мирасына җәлеп итү, эстетик тәрбияләү, конкурста катнашучыларның башкару осталыгын үстерү максатында үткәрелә.

2. Конкурсның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

1) балаларда туган телгә карата хөрмәт тәрбияләү;

2) укучыларны татар халкының рухи традицияләренә җәлеп итү;

3) укучыларның татар телендә иркен аралашу дәрәҗәсен күтәрү;

4) балаларның һәм ата-аналарның игътибарын татар әдәбиятына һәм укуга җәлеп итү;

5) белем бирү оешмаларында мәктәп яшендәге балаларның иҗади потенциалын үстерүгә шартлар булдыру;

6) балаларда лидерлык сыйфатлары формалаштыру;

7) профессиональ сәхнәгә чыгу юлы аша яшь талантларга ярдәм күрсәтү;

8) укучыларны шәһәр һәм республика конкурсларында, чараларында катнашуга әзерләү.

2 бүлек. Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибе

3. Конкурста шәһәр белем бирү оешмаларының татар телен белә торган 5-8 сыйныф укучылары катнаша ала.

4. Конкурста катнашу ирекле.

5. Конкурста катнашу өчен кандидатларны тәкъдим итү белем бирү оешмаларының коллективлары һәм ата-аналар тарафыннан гамәлгә ашырылырга мөмкин.

6. Конкурсны оештыру һәм үткәрү өчен, составы Башкарма комитет карары белән раслана торган оештыру комитеты төзелә.

7. Оештыру комитеты һәрбер этапта конкурс үткәрүгә йомгак ясый, шулай ук конкурс җиңүчеләрен билгели.

8. Конкурс өч этапта үткәрелә.

9. I этап 2023 елның 13 мартыннан 2023 елның 24 мартына кадәр белем бирү оешмаларында үткәрелә.

Конкурсның I этабы программасы ике өлештән тора:

1) «Визитка» - катнашучы индивидуаль формада яки ярдәм төркеме белән «Татарлыгым белән горур мин!» (5 минутка кадәрге чыгыш) темасына иҗади визитка күрсәтә;

2) озынлыгы 4 минуттан артмаган сәнгать номеры.

Конкурсның I этабы йомгаклары буенча II этапта катнашу өчен һәр белем бирү оешмасыннан берәр катнашучы кертелә.

10. II этап та катнашу өчен түбәндәге форма буенча заявка бирергә кирәк:

Заявка формасы

| О/о | Катнашучының Ф.И.А.и., сыйныфы (2в) | Җаваплы җитәкченең Ф.И.А.и., эл.почтсы, телефоны | Мәктәп этабында канашучыларның саны |
|---|---|---|---|
| | | | |

II этапта катнашучыларга түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:

1) иҗади визитка. Иҗади визиткаларны карау «14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге» МАМББУда (Чулман-88 (44/16), 202 каб.) узачак. Чыгышлар графигы өстәмә рәвештә мәгълүмати хат итеп белем бирү оешмасының электрон адресына җибәреләчәк;

2) тәкъдим ителгән темаларның берсенә видеоролик.

Видеороликларның темасы:

- «Җиде яктан җыелып килгән җиде ятның язмышларын җыйды данлы КамАЗ»;

- «Телнең, көйнең, гореф-гадәтләрнең

Бар үз моңы, бар үз хисләре» (Татарстанда 2023 ел-милли мәдәниятләр һәм горф-гадәтләр елы уңаеннан);

- «Сез - халкыбыз горурлыгы!» (Әлфия Авзалованың 90 еллыгына; Роберт Миңнуллинның 75 еллыгына; Луиза Батыр-Болгариның 70 яшьлек юбилеена багышлап эшләнгән видеороликлар);

- «Гаиләм тарихында гасырлар кайтавазы»;

- «Кешенең ихтыяр көченең чыганагы ышануда, иманда».

Видеороликны заявка белән бергә 2023 елның 27 мартына кадәр электрон адреска җибәрергә: saifullina@yandex.ru

11. Видеороликларга карата таләпләр:

Видеоролик теләсә нинди видеотөшерү чарасы (видеокамера, цифрлы фотоаппарат, мобиль телефон һ.б.) белән төшерелергә мөмкин.

Видеороликның формат: avi яки mp4.

Роликның озынлыгы: 3 минут.

Бирелә торган ролик файлының исемендә түбәндәгеләр булырга тиеш: гомуми белем бирү оешмасының исеме, авторның сыйныфы, Ф.И., конкурс эшенең исеме.

Видеороликларда түбәндәгеләр күрсәтелгән мәгълүмати заставка булырга тиеш:

- белем бирү оешмасының исеме,

-конкурсның исеме;

-авторның исеме, фамилиясе;

-конкурс эшенең темасы.

12. Видеороликларны бәяләү критерийлары:

1) видеороликның конкурс тематикасына туры килүе;

2) оператор съемкаларының, сурәтләрнең, тавышның, музыкаль бизәлешнең сыйфаты;

3) видеороликның мәгълүмати тулылыгы (теманы тулы ачу, эчтәлекнең максатка һәм бурычларга туры килүе, эшнең иҗади, тормышчан характеры);

4) тамашачыга эмоциональ тәэсире;

5) видеомонтажның сыйфаты (музыка һәм сурәтне синхронлаштыру, видекүчешләр, видеорәтнең оригинальлеге).

13. Визиткаларны бәяләү критерийлары:

1) татар телен белү;

2) сәхнәдә үзен тота белү;

3) актерлык осталыгы һәм сәхнә сөйләме дәрәҗәсе;

4) индивидуальлек;

5) музыканың, җырның, шигырьнең эчтәлеге балаларның яшенә туры килү;

6) концерт номерларының камиллеге;

6) костюмнарның зәвыклыгы.

14. II этапның 10 җиңүчесе конкурс финалында катнашу өчен тәкъдим ителә.

14. Финалистлар вокал, хореография буенча сәхнәгә куючы белән репитиция чорыннан һәм интеллектуаль викторина буенча консультацияләрдән торган махсус әзерлек узалар.

15. Финал өч конкурс биременнән тора:

1) визитка;

2) интеллектуаль викторина;

3) импровизация.

16. Конкурсның финалы 2023 елның апреле-маенда «Шатлык» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесендә шоу – программа рәвешендә үтәчәк.

## 3 бүлек. Конкурска йомгак ясау

17. Конкурста катнашучылар оештыру комитеты тарафыннан бәяләү критерийлары нигезендә биш баллы система буенча бәяләнә. Конкурска йомгак ясау беркетмә белән рәсмиләштерелә.

18. Иң күп балл җыйган катнашучылар конкурсның җиңүчеләре дип таныла.

19. Призлы урыннар түбәндәге номинацияләр буенча бирелә:

- 1че урын - «Татар малае - 2023»;
- 2 нче урын;
- 3нче урын;
- «Иң талантлы малай»;
- «Иң матур сәхнә образы өчен»;
- «Иң милли җанлы малай»;
- «Иң камил малай»;
- «Милли традицияләрдә тәрбияләнгән малай»;
- «Иң оста телле малай»;
- «Иң акыллы малай».

20. Конкурста җиңүчеләр дипломнар һәм истәлекле бүләкләр белән бүләкләнә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева